Татарстан РеспубликасыӘлмәтмуниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабря 2020 ел №10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенеңүз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүтәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 нче номерлы карары нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 107 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| «Вазыйфаныңисеме» | унбернче төркемхезмәтхакы, сум |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 17247,00 |
| Авылбашкарма комитеты җитәкчесеурынбасары | 16902,00 |

1.2. карарга2 нчекушымтадагытаблицаныяңаредакциядәбәянитәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме”

| | 11 төркем |
|---|---|
| Башлык | 17253,00 |
| Башлык урынбасары | 12397,00 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйлечы гымнарны финанс белән тәэминитүтиешлеелга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләречикләрендәгамәлгәашырыладипбилгеләргә.

3. Әлеге карарны Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт; Комсомол урамы, 12б йорты территориясендә; Акташ станциясе контора бинасында урнашкан махсус стендларда игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Рус Акташы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Рус Акташы
авыл җирлеге Башлыгы С.А.Белоногов